

Шушы исем астында 26 гыйнвар көнне Мордовия педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри осталыгын өзлексез арттыру үзәге “Педагог13.ру”да татар прозаигы, язучы-фронтовик Габдрахман Абсалямов иҗатына багышланган төбәкара фәнни-гамәли конференция үтте. Анда офлайн форматта Мордовия, Пенза өлкәсе милли мәктәпләре укытучылары һәм онлайн форматта төрле регион вәкилләре катнашты.      Чараның модераторы Елена Михайловна Наумова, “Педагог 13.ру”ның этномәдәни белем бирү лабораториясе мөдире, чарада катнашучыларны сәламләде.
Көн тәртибе буенча, “А.С.Пушкин” исемендәге Мордовия китапханәнең туган якны өйрәнү әдәбияты бүлегенең баш китапханәчесе Альфия Нургаян кызы Маланьчева “Габдрахман Абсалямовның тормышы һәм иҗаты татар халкының милли мәдәнияте контекстында” темасын яктыртып чыгыш ясады. Наилә Хәлил кызы Насырова, Мордовия правительствосының “Юлдаш” иҗтимагый-сәяси газетасы корреспонденты чыгышында “Габдрахман Абсалямов - йөрәкләрдә сүнмәс утлар кабызган әдип” дип сөйләде.



Пенза өлкәсенең Каменский районы Кикино урта мәктәбенең татар теле һәм татар әдәбияты укытучысы Равилә Фәрит кызы Баткаева Габдрахман Абсалямов иҗатында мәхәббәт темасын яктырткан чыгышын тыңладык.
Габдрахман Абсалямов иҗатын һәм тоткан урынын яктыртып, Россия халыкларының тарихи-мәдәни мирасының хәзерге мәктәп укучыларының патриотизмын формалаштырудагы роле турында “Педагог 13.ру”ның этномәдәни белем бирү лабораториясе методисты Вера Александровна Маскаева белән Ковылкино урта мәктәбенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы Ирина Павловна Малышева, Ләмберә районы Черемиш топ мәктәбенең рус теле укытучысы Жаннат Фаиль кызы Илькаева, Ләмберә районы Пензятка урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Равза Мукаддяс кызы Юмаева, Рузаевка районы Татар Пешлә урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Сания Спартак кызы Саляева шул ук районның Болдово урта мәктәбенең татар, рус телләре укытучысы Наилә Идрис кызы Башмакова, Ләмберә районы Черемиш топ мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Фазия Фәрит кызы Боярова сөйләделәр.
Мордовиябез җире сәләтле кеше-ләргә бай. Шулар арасында классик язучыларыбыз. Регионыбыз халкы Шәриф Камал, Һади Такташ һәм Габдрахман Абсалямов белән горурлана, ярата. Алар турында мәктәпләрдә киләчәк буын вәкилләребез белем ала. Горурланып, зурлап төрле чаралар үткәрәбез.
- Менә бүген йөрәкләребездә сүнмәс утлар кабызган күренекле язучы, пуб-лицист, тәрҗемәче, җәмәгать эшлек-лесе Габдрахман Абсалямов турында сүзебез. Ул 1911 елның 28 декабрендә хәзерге Мордовия Республикасының Ковылкино районы Иске Аллагол авылында дөньяга килә. Классик язучыларыбыз туган авылларында - Шәриф Камалның Татар Пешләсендә, Һади Такташ Сыркыдысында ничәмә-ничә тапкыр булган

идем, ә Габдрахман Абсалямовнын – юк, дип фикерләрем белән уртаклаштым. - Хыялымны тормышка ашырып, 2010 ел жәенен берсендә, Краснослободск-Ковылкино трассасыннан 18 километр читкә урнашкан Иске Аллаголда булдым. Авылга кергәчтен, урамнын ун ягында урнашкан йорт ишек алдында, Надия Кәлимулла кызы белән Шамиль Равиль улы Кузнецовлар янына тукталдым. Аллагол турында сорашкач, килvемнен сәбәбе турында әйттем. Шул арада авыл халкы һәм Мәскәvдән жәйге ялга кайткан кунаклар яныбызга жыелды. Озак аралаштык. Халык хәтерендә Габдрахман Абсалямов яши: авылдашлары рәхәтләнеп анын турында белгәннәре белән уртаклашты. Бvген язучынын исемен йорткән урамда яшәгән өйләре урынын кvрсәттеләр, Габдрахман Абсалямов исемен йорткән колхоз турында, мәктәп бинасындагы истәлекле такта турында да сөйләделәр. Казаннан кайткан кунакларны да хәтерләрендә саклыйлар. Габдрахман Абсалямовнын оныгы Альбина Булат кызы бабасы яшәгән Иске Аллагол авылынын Тюкай (бvген Г.Абсалямов) урамыннан 2009 елны йөреп vткән. Мин дә шул урында булдым. Әмма йортлары кvптәннән юк.
Якташ язучыларыбыз безнен кvнелләрдә һәм аларнын исемен киләчәк буынга мәнгеләштерv юлы белән дә истәлекле урыннарны калдырырга тырышыбыз. Татарстанда классик язучыларнын исемнәре мәнгеләштерелгән. Без дә якташ язучыларыбыз белән горурланып яшибез. Мәсәлән, якташ язучыбыз Шәриф Камал исемен Рузаевка районы Татар Пешлә мәктәбе йөртә, мәктәптә Ш.Камал музее эшли, туган йорты урынына истәлекле такта куелган. Һади Такташыбызнын Торбеево районы Сыркыды авылында музее эшләп килә. Ковылкино шәһәренен 4 номерлы мәктәбендә Габдрахман Абсалямов экспозициясе эшли, Иске Алагол урамы Габдрахман Абсалямовнын исемен йөртә. Колхозлар бvген булмаганга, анын исемен йорткән хужалык та юк. Авылда мәктәп тә юк. Әмма Рес-публикабыз житәкчеләре бу олкәдә дә эшлиләр. Габдрахман Абсалямов исемен мәнгеләштерv юбилейларда гына тvгел, ә башка вакытларда да алып барыла. Юбилей дигәч, тагы бер истәлек. 2011елны якташ язучыбызнын 100-еллык Юбилее унаеннан Ковылкино шәһәрендә һәм Ромодан районы Белозерье авылы мәктәбендә тантаналы рәвештә чаралар vтте. Азёрка мәктәбендә булган чарада мин дә катнаштым. Альбина Булат кызынын бабакае турындагы истәлекләрен vз авызыннан тынларга насыйп булды. Ул шунда Мордовиябезгә - анын халкына, житәкчеләренә бабасынын исемен мәнгеләштерv очен рәхмәт сvзләрен янгыратты. Мордовиябезне, кендек каны тамган бабасы, әбисе жирен (биредә vсмәсә дә, жәйләрен ял итмәсә дә) ихластан ярата. Милли мирасыбыз алдында баш ия. Читтә яшәгәннәр чын мәгънәсендә нәсел жепләрен югалтмаска тырышалар. Без дә туган олы һәм кече Ватаныбызны ихластан яратабыз.
Әйтеп киттем, якташ шәхесләребез кvнелләребездә сvнмәс ут булып яна. Габдрахман Абсалямовнын тормыш иптәше Магинә Исмаил кызы Чумарина тумышы белән Ковылкино районына кvрше булган Торбеево районы Татар Юнки авылыннан. Шулай, 2012 елны Татар Юнки топ мәктәбендә, Габрахман Абсалямовнын музее ачыла. Бу тагы бер тапкыр Габдрахман Абсалямовнын безнен йөрәкләрдә булуына дәлил. Кунакка Альбина Булат кызы да кайта һәм кvнеленә якын экспонатларын: 5 томда бабасы әсәрләрен, ана атап язылган хатларын, кvзлеген, солдат букчасын, әбисенен энесе - Советлар Союзы герое Әхмәт Чумариннын фотосын музейга бvләк итә.
Менә биредә утырган укытучылар якташ язучыларыбыз тормыш һәм ижат юлын укычыларына өйрәтә, иншалар язалар, чаралар vткәләр. Мордовия кvләмендә “Педагог13.ру”да тобәкара фәнни-гамәли конференция vтә. Болар барысы да

Габдрахман Абсалямов- йорәкләрдә “сүнмәс утлар” кабызган әдип икәненә дәлил.

**Наилә НАСЫРОВА**